ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 8 июнендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $8^6$ пункт өстәргә:

«$8^6$) үзләрен көчләп күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану турында сораучы, күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затлар, әгәр алар социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә, үзләрен күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тануга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирүгә яисә Россия Федерациясе гражданлыгы бирүгә бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр;»;

2) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 22 пункт өстәргә:

«22) әлеге статьяның 1 өлешендәге $8^6$ пунктында күрсәтелгән затларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү, аларны күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану, аларга Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү, аларга Россия Федерациясе гражданлыгы бирү, юридик әһәмияткә ия булган

фактларны билгеләү һәм әлеге мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле булган югалган документларны торгызу.»;

3) 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) үзләрен көчләп күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану турында сораучы, күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип танылган йә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затлар булсалар – юридик әһәмияткә ия булган фактларны билгеләүгә һәм социаль ярдәм чаралары алу, күченеп килергә мәҗбүр булганнар, качаклар дип тану, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү яисә Россия Федерациясе гражданлыгы бирү өчен кирәкле булган югалган документларны торгызуга бәйле мәсьәләләр буенча.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 19 июнь
№ 34-ТРЗ